Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
Республики Татарстан
423644, Менделеевский район, с. Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы
423644, Менделеевск районы, Монашево авылы,
Мэктэб урамы, 19

тел./факс 8/85549/3-73-18
E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09.07.2024 ел № 7

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
«Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләре проекты буенча
гавами тыңлаулар уздыру турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 - 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге уставы, гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе нигезендә, Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 8 августы 17 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Монашево авылы, Ленин урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән сорау буенча түбәндәге составта гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен комиссия төзергә:

Иосифов Р.Ф. - Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Мальгин Г.А. – Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге рәисе урынбасары, комиссия рәисе;

Иванов Г.Н.– Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге советы депутаты, комиссия әгъзасы.

3. 2024 елның 9 июленнән 8 августына кадәр Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча материаллар экспозициясен Татарстан Республикасы, Менделеевск районы,

Монашево авылы, Ленин урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 423644, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Монашево авылы., Мәктәп ур., 19 йорт адресы буенча ( Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге башлыгы исеменә) кабул ителә (җибәрелә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Монашево авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

ТР Менделеевск муниципаль районының
Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Иосифов